29.08.2025 үткән педагогик киңәшмәдә

расланды. Беркетмә №1.

Балалар бакчасы мөдире: ____________

Л.Г.Фәйзрахманова

# Арча муниципаль районы Яңа Кырлай балалар бакчасының 2025-26 нчы уку елына эш планы

**ПЛАННЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ**

Эчтәлек..........................................................................................................................2
Кереш ..............................................................................................................................3
Узган уку елына анализ................................................................ ........................5
Максат һәм бурычлар.............................................................................................10
Педагогик киңәшмәләр..........................................................................................11
Бәйрәмнәр...............................................................................................................13
Сәламәтләндерү эше...............................................................................................14
Тәрбия һәм белем бирү эшенә җитәкчелек итү һәм контроль..............................................17
Юл-транспорт травматизмын кисәтү.......................................................................19
Хезмәткәрләр белән коллектив җыелышлары.....................................................20.
Оештыру эшләре.....................................................................................................21
Кадрлар белән эш....................................................................................................22
Административ - хуҗалык эшләре.........................................................................25
Күргәзмәлекләр.......................................................................................................27
Әти-әниләр белән эш..............................................................................................29

**1.Кереш**

**Балалар бакчасы турында гомуми мәгълүмат**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Яңа Кырлай балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе” 2006 елдан бирле мәктәп белән бер бинада балалар тәрбияләүдә үзенең эшен алып бара.

Юридик адресы: 422035, Яңа Кырлай авылы,Үзәк урам,2 нче йорт.

Балалар бакчасы Яңа Кырлай мәктәбе бинасында икенче катта урнашкан.Мәктәп өч катлы,стенасы кирпечтән. Балалар бакчасы мәктәп бинасына 2006 елда күчерелде. 2015нче уку елында тәрәзәләр алмашынды. Су кергән,канализация бар. Бина газ белән җылытыла.

- Йокы бүлмәсе
- Уен бүлмәсе
- Раздаточная
- Киенү бүлмәсе
- Санузел
- Подсобная

Әлеге бүлмәләр тиешле җиһазлар белән тулыландырылган.
Участокта уйнар өчен кирәкле шартлар бар.

Бакча 22 урынга исәпләнгән, 21 бала йөри.
Милләтләр төрлелеге:
- татарлар 100% тәшкил итә.

Бакча 9 сәгать эшли. ( 7.00 – 16.00 кадәр )

***2. Педагогик кадрлар.***

Балалар бакчасы тулысынча педагогик кадрлар белән тәэмин ителгән.

| **№** | **Педагоглар исеме** | **Профессиясе** | **Туган көне** | **Белеме** | **Ставка** | **Кат.** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Фәйзрахманова Ләйлә Габделфәт кызы | Мөдир | 29.04.1977 | югары | 1 | |
| 2. | Сафина Вәсилә Гарифҗан кызы | Тәрбияче | 12.03.1968 | югары | 0,83 | 1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Шакирова Алсу Госман кызы | Тәрбияче | 24.02.1991 | Югары | 0,5 | |

*3.Башка категориядәге хезмәткәрләр.*

| № | Исем-фамилиясе | Һөнәре | Белеме | Ставка |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Шакирова Гөлназ Ваил кызы | кече тәрбияче | Урта | 1 |
| 2. | Файзиева Гөлнара Рафаил кызы | пешекче | Югары | 1 |

***3. Балалар бакчасы түбәндәге программалар буенча эш алып барды:***

1.” - Комплексные занятия по программе «От рождения до школы» под редакцией Н.Е. Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А. Васильевой. Вторая младшая группа. – Изд. 2-е. – Волгоград: Учитель, 2013;

2. ”Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү”-К,В,Закирова, Р.А.Борһанова

3. Шәехова Р.К. “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”. Казан 2012 ел;

4.” Балалар бакчаларында сәйләм телен үстерү программасы”. К.З.Закирова

5. Гаиләдә,балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасы.

6. Мәктәпкәчә тәрбияләү программасы.

***4. Ата –аналар турында белешмә:***

Барлык гаилә - 21
Барлык ата-ана – 41
Тулы гаиләләр – 20
Тулы булмаган –1
Күп балалы гаиләләр – 7

**Балаларның яшькә карап бүленеше:**

| | Барлыгы | 1 яшь | 2 яшь | 3 яшь | 4 яшь | 5 яшь | 6 яшь |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Балалар саны | 21 | | | 4 | 4 | 4 | 9 |
| Малайлар | 8 | | | 2 | 1 | 2 | 3 |
| Кызлар | 13 | | | 2 | 3 | 2 | 6 |

**Авыл җирлегендәге 1 яшьтән 7 яшькәчә балаларның бакчага йөреше:**

2024 ел –80%

2025 ел – 84%

**Балаларның сәламәтлек төркемнәренә бүленеше:**

| | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|
| I төркем | 13 | 16 |
| II төркем | 8 | 9 |
| III төркем | 0 | 0 |

Балаларны сәламәт, физик яктан чыныккан шәхес итеп тәрбияләү өчен тәрбияче бакчада күп төрле үтемле чаралар куллана:

- Кояш һәм һава ванналары;
- Җылы вакытларда иртәнге гимнастиканы ачык һавада үткәрү;
- Җылы вакытларда участокта ялан аяк йөрү;
- ОРЗ, грипп вакытларында сарымсак төймәләре куллану, бүлмәгә чи суган кую;
- Аю табанын кисәтү максатыннан вак предметлар тегелгән келәмнәрдә йөрү.

**2024-2025 нче уку елына анализ**

Балалар бакчасы 2024-2025 уку елында түбәндәге бурычларны алган иде:

1. Балаларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген саклау.
2. Бакчасының эшен активлаштыру, педаголарның белемен үстерү.
3. Ике телдә дә тиешле дәрәҗәдә тәрбия процессын оештыру.ФГОС һәм УМК алымнарын даими кулланү.

4. Мәктәп белән эшне дәвам итү.ФГОС.

2024-2025 нчы уку елында балаларга тәрбия-белем бирү эше үз югарылыгында алып барылды, еллык план буенча эшләнәсе эшләрнең барысы да үтәлде.

Балалар бакчасы ел буе балаларга эзлекле белем бирү, физик яктан чыныккан, сәламәт, табигатьне саклый белүче балалар тәрбияләү бурычлары өстендә эшләде. Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр, белем-тәрбия бирүдә инновацион технологияләр кулланылды.

Бакчада балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игьтибар ителде.

Мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучылары белән ныклы элемтәдә торабыз: алар елга берничә тапкыр балалар бакчасына шөгыльләр карарга киләләр, гомуми киңәшмәләрдә, ата-аналар җыелышларында катнашалар.

Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсьәләләрнең берсе. Шуннан чыгып үз алдыбызга түбәндәге бурычларны куйдык:

- хәрәкәт - бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- туклану - бала организмы өчен иң мөһим шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
- организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр баланың үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
- балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;
- мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына. Шуларны истә тотып, баланың һәрьяклап үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Кыскасы, балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Арча больницасы участок педиатры тарафынан балаларны тикшерү

үткәрелде.  Тәрбиячебез көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес оештырды. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура  шөгыльләрендә  иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, дәрес уздыру төрләре үзгәртелде,  яңалыклар кулланылды.

Бакчада физкультура   шөгыле зурлар төркемендә өч тапкыр уздырылды – шөгыльнең берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада узды. Шөгыльләрдә  түбәндәге мәсьәләләрне тормышка ашырдык:

- балаларның үсешенә һәрвакыт игътибарлы булу;
- балаларга тормышта кирәкле хәрәкәт күнекмәләре бирү;
- сәламәтләндерү, чыныктыру эшенә шартлар булдыру;
- балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, көчен, җитезлеген үстерү;
- сәламәтләндерү юнәлешендә төрле физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗ булдыру;
- заман таләпләренә туры килгән программалар куллану, яңалыкка омтылу.

Грипп, ОРЗ чорында фельдшер  группада сарымсак ингаляциясе ясады. Группа тәрбиячесе сарымсактан төймә ясап, балаларга такты. Эшебезнең нәтиҗәсе - грипп эпидемиясе вакытында бакча карантинга ябылмады, авыручы балалар саны да аз булды.Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк- кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде. Кыш көне шуар өчен бакча ишегалдында балалар белән бергәләшеп кардан тау, урамга шугалак ясап куйдык. Кыш буе балалар рәхәтләнеп шуларда шудылар, уйнадылар.

Чыныктыру, сәламәтләндерү процедураларын башкарганда тәрбияче түбәндәге гигиена шартларын һәм таләпләрен төгәл үтәде:

- бүлмә һавасының саф булуы;
- бинадагы һава температурасының нормада булуы;
- киемнәрнең һава температурасына карап дөрес сайлануы;
- актив хәрәкәт режимы.

Бу юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналарга да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен  формалаштыру принципларын өй шартларында да үтәү кирәклеген искәртеп тордык.

Менюда ризыклар төрләндерелде, балалар аксымга бай продуктлар, яшелчә, ел әйләнәсендә җиләк-җимеш  белән тукландырылды.

Дөрес туклану, көндәлек режимны, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте: алар азрак авырды.  Күп еллар дәвамында беренче мәсьәлә булып балаларның тормыш иминлеген  һәм сәламәтлекләрен  саклау тора. Бу мәсьәләне тормышка ашыруда бакчада төрле чыныктыру процедуралары үткәрелә.( су белән аякларын юу ,тозлы сукмак,нокталы массаж).

Балалар бакчасы ике  юнәлештә эшне дәвам итте:

1. Интеллектуль үсеш.
2. Чыныктыру һәм сәламәтләндерү.

Сәламәт һәм чыныккан бала тәрбияләү буенча эзлекле эш алып барылды.Һәр баланың физик күрсәткечләрен индивидуаль  исәпкә алып үткәрелгән чаралар  матур нәтиҗә  бирде.

Балалар бакчасында укыту-тәрбия программасы эчтәлеге һәм яңа технологияләр кулланып,комплекслы программалар нигезендә “Салават күпере”, ”Экологик тәрбия” программасы, ”Татар мәдәнияты” программасы һәм  “Әхлак тәрбиясе белән таныштыру” программасы балаларның  сөйләм теле үсешенә уңай йогынты ясый.

**Балалар белән “Т.Р. телләр турында законын” тормышка ашыру буенча ике юнәлештә эш алып барылды:**

1. Татар һәм рус теленә өйрәтү.
2. Ике телдә дә тиеш дәрәҗәдә тәрбия процессын оештыру.,ФГОС һәм УМК алымнарын һәрдаим куллану.

**Татар һәм урыс теленә өйрәтү өч юнәлештә алып барылды.**

**1.** Телне өйрәнү.

**2.**Туган як һәм аның табигате белән танышу.

**3**.Татар һәм урыс халкының мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итү.

Шул ук вакытта ТРИЗ системасының элементлары төрле дидактик һәм бармак уеннарында  кулланылды.Халык авыз иҗатын өйрәнүгә  зур игьтибар бирелде.

Балалар бакчасы башлангыч мәктәп белән тыгыз элемтәдә тора. Төрле кичәләр , чаралар мәктәп балалары белән берлектә үткәрелә. Мәктәптә үткәрелгән башлангычлар атналыгында  балалар татар халкының “ Су анасы ”әкиятен сәхнәләштерделәр. Башлангычлар белән берлектә тагын берничә чара   уздырылды. (Балалар яклау көне, әниләр бәйрәме, мәктәпкә озату, сабантуй).

Район семинарларында катнашып алдынгыларның эш тәҗрибәсе өйрәнелде, район балалар бакчаларында ачык шөгыльләрдә тәҗрибә тупланылды.

Балалар бакчасы ата-аналар белән тыгыз элемтәдә эшләгәндә генә югары уңышларга ирешә ала. Ата-аналар бакчага бик теләп ярдәм итәләр. Ата-аналар чакырылып бәйрәмнәр үткәрелде. Бәйрәмнәрдә төрле-төрле конкурслар, әңгәмәләр уздырылды. Һәрбер гаилә үз альбомын төзеде.

Укыту-тәрбия процессын күзәтүләрдән һәм анализлардан чыгып әйткәндә, югары күрсәткечләргә ирешер өчен түбәндәге тәрбия эшләренә басым ясарга кирәк:

- балаларны тормыш куркынычсызлыгына ,үз сәламәтлеген кайгыртырга өйрәтү буенча эшне җанландырырга,юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтүгә эти-әниләрне җәлеп итәргә;
- Мәктәп һәм бакча арасындагы элемтәне ныгыту.
- Кече яшьтәге балаларның кул моторикасын үстерү.
- Балаларга патриотик тәрбия бирүне дәвам итү.
- Мәктәпкә хәзерлек төркеме белән системалы эш.
- Балаларның мөстәкыйль уен эшчәнлеге, музыка, сәнгать белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру.

Башлангыч класска киткәндә бала сөйләмендә кимчелекләр булмаска тиеш. Бу - балалар бакчасының изге бурычы, чөнки без - тәрбиячеләр, мәктәпкә авазда кимчелекләрне төзәтеп җибәрергә тиешбез. Тәрбиячебез һәр баланың нинди аваз кимчелеге барлыгы турында хәбәрдар. Шуңа күрә ел буена авазларны, сүзләрне дөрес әйтү культурасын тәрбияләү, үз фикерләрен, кичерешләрен аңлатканда җөмләләрне тел нормаларына туры китереп, ачык, дөрес әйтү, дөрес дикция белән сөйләшергә өйрәтү өчен балаларга төрле күнегүләр өйрәтте, ата-аналарга киңәшләр бирде, аларны ачык дәресләргә чакырды. Мәктәпкә хәзерлек төркемендә мониторинг үткәрелде.8 баладан алты бала югары , ике бала уртача бал җыйдылар.

Һәр ел фасылын зур оешканлык белән каршы алдык. Язын тирә-якны чистартып, апрельдә чәчәк үсентеләре утыртып каршыладык. Бакчадагы язгы эшләр белем-тәрбия бирү эшләре белән чиратлап алып барылды: язгы су юлларын ачу, стена буендагы карны чистарту, бакча мәйданын җыештыру уздырылды, чәчәкләрне тәрбияләп үстерү, сирәкләү, су сибү – болар барысы да бакча хезмәткәрләре тарафыннан эшләнде. Көзне каршылап участоктан чәчәк орлыклары, яфраклар җыйдык, мәйданны коелган яфраклардан арындырдык. Кышны каршы алганда исә, кардан сыннар ясау, кар көрәү,

тубәләрне боздан, кардан арындыру кебек эшләр эшләнде, кошларга җим салыр өчен җимлекләр элдек, аларга җим салуны оештырдык, агач төпләренә салкыннан саклар өчен кар өйдек.

Балаларның экологик яктан белемнәрен киңәйтү, тирәнәйтү максатыннан тәрбияче табигать материаллары туплап, төрле сувенирлар, паннолар ясады. Бүлмәләрдә бик күп төрле гөлләр үстердек. Тәрбияче балалар белән берлектә гөлләрне карап, тәрбияләп, гөлләрне таныргa, исемнәрен әйтә белергә өйрәтте. Мөдир белән берлектә тәрбияче иҗат почмагы ясады. Балалар һәм тәрбияче төрле бәйге-ярышларда катнашты.

Бу эшләр белән беррәттән бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә булган мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә салына.

Яңа 2025-2026 нчы уку елына әзерлек эшләре дә үз югарылыгында алып барылды. Ремонт эшләре башкарылды, бүлмәләр җыештырылды, тәрәзә пәрдәләре яңартылды, тәрәзәләр юылды,жалюзи куелды, складлар җыештырылды,ишек алды зәвыкъ белән бизәлде,матурланды,чәчәклекләр җәен дә, көзендә балкып торды.Балаларга уйнар өчен ишегалды инвентарьлары төзекләндерелде.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып,шулай ук узган уку елы проблемаларын исәпкә алып 2025 - 2026 нчы уку елына балалар бакчасының максаты:
Сәламәт,культуралы, яшь үзенчәлекләренә туры килгән белем-күнекмәләр үзләштергән, рус һәм татар телләрен камил белгән,белем алганда ФДББС ын кабул итә алырлык шәхес тәрбияләү.

## 2025-2026 уку елына түбәндәге бурычлар билгеләнде:

**1** . Балаларның физик һәи психик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту. Балаларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген саклауда физкультура-чыныктыру эшен дәвам итәргә.

2. Уку-укыту медотик кулланмаларына (УМК) таянып,ике дәүләт теле – рус һәм татар телләрен өйрәтүдә яңа алымнар куллануны дәвам итү, аралашуны бары тик туган телдә алып бару.
3.Педагогларның федераль дәүләт белем бирү стандартларын өйрәнеп,белем һәм тәрбия бирү эшчәнлегендә осталыкларын үстерү.

4. Балаларның кече яшьтән үк төрле яклап сәләтләрен үстерү.

5. Гаилә һәм балалар бакчасының эшен активлаштыру, гаилә белән бәйләнешне ныгыту.

## Педагогик киңәшмәләр

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | **Тема: “Балалар бакчасында белем һәм тәрбия бирү,балаларның сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру.”**<br>1.Балалар бакчасының узган 2024-2025уку елының белем һәм тәрбия эшенә нәтиҗә.Яңа 2025-2026 уку елына бурычлар.<br>2.Яңа уку елына түбәндәге документларны карау һәм раслау<br>- еллык эш планнары<br>-еллык календарь укыту графигы<br>-турыдан – туры белем бирү эшчәнлеге челтәре<br>-режим<br>-эштә куллана торган программа,методик ярдәмлекләр<br>- педагогның эш программалары<br>- диагностика уздыру графигы<br><br>3.Яңа уку елына педагогик киңәшмәнең сәркатибен сайлау,раслау | сентябрь | мөдир тәрбияче |
| 2. | **Тема: “Сәламәт булыйк”**<br>1. Узган педагогик киңәшмәнең карар үтәлешен тикшерү.<br><br>2. Авырулар буенча анализ ясау.<br>3. Бакча шартларында балаларны чыныктыру системасының торышы, дөрес туклану культурасы.<br>4. Балаларның сәламәтлеген саклауда гаилә һәм балалар бакчасының бердәмлеге, кечкенәләр төркемендә адаптация.<br><br>5. Уку елы башында (сентябрь) уздырылган мониторинг нәтиҗәләренә анализ | декабрь | Мөдир тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | **Тема:« Гаилә һәм балалар бакчасы: бердәм эшчәнлек аспектлары"**<br>1.Узган педагогик киңәшмәнең карар үтәлешен тикшерү.<br>2.Бакча-бала-әти-әниләр" бердәм эшчәнлеген оештыру, балаларга дәүләт телләрен өйрәтү алымнары.<br>3.Ата-аналарны төркем тормышына катнаштыру-балага якын килүнең бер алымы.<br>4.Ата-аналар белән аралашу сферасында педагогларнын компетентлыгы.<br>5.Психологик зарядка. Тематик тикшерү нәтиҗәләре.<br>6.Карар кабул итү һәм раслау. | март | Мөдир тәрбияче |
| 4. | **Т е м а: " Педагогик коллективның эшчәнлек нәтиҗәләре"**<br>1. Узган педагогик киңәшмәнең карар үтәлешен анализлау.<br>2. 2025-2026 уку елының белем һәм тәрбия бирү юнәлешендә еллык эш планының үтәлеше,тәрбияче-нең еллык эшләренә отчет.<br>3. Мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының мәктәпкә әзерлеген тикшерүгә уздырылган диогностика нәтиҗәләре.<br>4. Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту юнәлешендә эш планы үтәлешенә аналитик,чагыштырулы нәтиҗә.<br>5. Карар кабул итү һәм раслау. | Май | мөдир тәрбияче |

**Бәйрәмнәр планы.**

| Үтәү вакыты | Эшнең эчтәлеге | Эшнең төре | Кем җаваплы |
|---|---|---|---|
| **Сентябрь** | 1."Белем бәйрәме" | Мәктәпкә экскурсия | тәрбияче |
| **Октябрь** | 1."Ачык сандык" - өлкәннәр көнен билгеләп үтү.<br>2. Алтын көз "Сөмбелә"<br>3. "Нәни Сөмбелә" район конкурсында катнашу | Фольклор кичә-күңел ачу кичәсе<br><br>Бәйрәм<br>Конкурс | Тәрбияче<br><br>Тәрбияче |
| **Ноябрь** | 1."Көзләрдә дә каршы алабыз әниләрнең бәйрәмен"<br>2.Педагоглар арасында мастер-класс | Кичә<br><br>Конкурс | Тәрбияче<br><br>Тәрбияче |
| **Декабрь** | 1."Без кышны яратабыз" – саф һавада чаналар белән уеннар.<br>2."Хуш киләсең,Яңа ел!"<br>3. "Голосок"<br>4.Кардан фигураларга һәм яңа ел бизәлеше. | Эстафета<br><br>Бәйрәм кичәсе<br><br>Конкурс<br>Конкурс | Тәрбияче<br><br>Бакча коллективы<br><br>Тәрбияче<br>Тәрбиячеләр |
| **Январь** | 1."Кышкы бакчада!"<br>2."Кошларга җимлек"<br>3.Әкиятләр сәхнәләштерү. | Конкурс<br><br>Театраль тамаша | Бакча коллективы<br>Тәрбияче |
| **Февраль** | Әтиләр бәйрәме<br>"Әти белән көчле мин" | Бәйрәм кичәсе | Тәрбияче |
| **Март** | "Әнием алтыным"<br>Нәүрүз бәйрәме. | Музыкаль кичә | Тәрбияче |
| **Апрель** | 1. Кошлар бәйрәме<br>2.Тукай безнең күңелләрдә. | Күңел ачу кичәсе<br>Шигырь бәйрәме | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Май** | “Җиңү бәйрәме”<br>“Сау бул бакча, исәнме мәктәп”<br>“Балаларны яклау көне” | Бәйрәм<br>Күңел ачу кичәсе<br>Бәйрәм<br>Конкурс,эстафеталар. | Бакча коллективы тәрбияче |

## Балалар бакчасында сәламәтләндерү эше.

| № п/п | Эш төре | Үтәлеш | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. Оештыру эшләре | | | |
| 1.1 | Көнлек режимны оештыру һәм күзәтү | Даими | тәрбияче |
| 1.2 | Физик тәрбия, “сәламәтлек” папкасын тулыландыру | Даими | тәрбияче |
| 1.3 | Медицина тикшерүе нәтиҗәләрен һәм авыруларны анализлау | ай саен | тәрбияче |
| 1.4 | “Сәламәтлек” көне үткәрү | Даими | тәрбияче |
| 1.5 | - яктылык режимын<br>- $t^0$ режимын<br>- һава режимын<br>- юеш җыештыруны үтәү | даими | мөдир<br>тәрбияче |
| 2. Сәламәтләндерү чаралары | | | |
| 2.1 | Балаларны иртән тикшереп кабул итү | Даими | тәрбияче |
| 2.2 | Иртәнге гимнастика ясату | Даими | тәрбияче |
| 2.3 | Физкультура дәресләре үткәрү | Даими | тәрбияче |
| 2.4 | Саф һавада хәрәкәтле уеннар | Даими | тәрбияче |
| 2.5 | Һава, кояш ваннасы алу | Даими | тәрбияче |
| 2.6 | Су процедуралары үткәрү | Даими | тәрбияче |
| 2.7 | Йокыны оештыру | көн саен | тәрбияче |
| 2.8 | Культура-гигиена күнекмәләре бирү | көн саен | тәрбияче |
| 2.9 | Сәламәтләндерү гимнастикасы<br>Коррекция эшләре ( аю табанлылыкны профилактикалау буенча күнегүләр) | Даими | тәрбияче |
| 2.10 | Дәресләр вакытында физкультминуткалар үткәрү | Даими | тәрбияче |
| 2.11 | Саф һавада йөрү | Даими | тәрбияче |
| 2.12 | Чыныктыру: Су һәм | Даими | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | һава белән чыныктыру күнекмәләре бирү | | |
| 3. Дәвалау профилактика эше. | | | |
| 3.1 | Профилактика прививкаларын ясау | план буенча | фельдшер |
| 4. Туклануны оештыру | | | |
| 4.1 | Көнгә 4 ашатуны оештыру | көн саен | мөдир |
| 4.2 | Ризыкны витаминлаштыру | көн саен | пешекче |
| 4.3 | Ризыкның саклану срогын карау | Даими | пешекче |
| 4.4 | Тукландыру нормасын үтәү | Даими | мөдир |
| 5. Профилактик чаралар | | | |
| 5.1 | Санитар-өйрәтү эше:<br>консультацияләр,әңгәмәләр,<br>семинарлар, лекцияләр | Даими | мөдир |
| 5.2 | Балаларның имгәнүен булдырмау буенча чаралар үткәрү:<br>Куркынычсызлык инструкциясен үтәү<br>Балалар белән әңгәмәләр үткәрү<br>Шөгыльләр үткәрү | Даими | тәрбияче |
| 5.3 | Йогышлы чирләргә профилактик чаралар:<br>-сарымсак һәм суган куллану<br>-оксалиновая мазь куллану | Даими | коллектив |
| 5.4 | Спортлы күңел ачулар | айга бер | коллектив |

## “Сәламәтлек көнен” оештыру планы.

| № | Эшнең төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | “Көзге марафон” – спорт бәйрәме | X | Тәрбияче |
| 2. | Группада чыныктыру процедураларын оештыру һәм үткәрү. | XI | Тәрбияче |
| 3. | Кышкы бәйрәм – Нардуган. “Кем тизрәк киенә” | XII | Тәрбияче |
| 4. | “Курыкмыйбыз суыктан” Саф һавада уеннар. | I | Тәрбияче |
| 5. | 1.“Чаңгы юлы” Саф һавада балалар белән эстафета<br>2.Хәрби уен “Солдат котелогын эзлибез” | II | Тәрбияче |
| 6. | Милли музыкаль бәйрәм “Карга боткасы” КВН | III | Тәрбияче |
| 7. | Көлке көне.Кем шаян? (“ Киресен эшләү”)<br><br>7- апрель бөтендөнья сәламәтлек көне. Әңгәмә | IV | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | Татар халык фольклорын кулланып “Язгы күңел ачулар”.<br><br>Җәйге бәйрәм - “Сабантуй”.<br>Татар халык уеннары | V | Тәрбияче<br><br><br>Тәрбияче, мөдир |

**Тәрбияченең балалар белән эшләвен өйрәнү.**
**Укыту-тәрбия процессына педагогик контроль**

| № | Эчтәлек | Вакыты | Җаваплы кеше |
|---|---|---|---|
| 1. | Тәрбияченең календарь-тематик планнарын тикшерү | Сентябрь-октябрь | мөдир |
| 2. | Балалар бакчасында көндәлек режимның үтәлеше. | Даими | тәрбияче |
| 3. | Балаларның тормышын һәм сәламәтлекләрен саклау инструкциясенең үтәлеше:<br>- Укыту-тәрбия эшчәнлеге<br>- Балаларның бакчага йөрешен тикшерү<br>- Хезмәтне саклау,куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү | Һәр көн | тәрбияче |
| 4. | Күңел ачу кичәләренең үтәлеше | График буенча | Мөдир тәрбияче |
| 5. | Сәламәтләндерү эшләре. | Ай саен | тәрбияче |
| 6. | Педсовет карарының үтәлеше. | График буенча | мөдир |
| 7. | Тәрбияченең УМК Белән эшләү үтәлеше. | Даими | тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | Балаларның авырып калдырган көннәрен тикшерү. | Ай саен | мөдир |
| 9. | Укыту- тәрбия программасының үтәлеше. | Даими | мөдир |

## Фронталь тикшерү

| № | Эчтәлек | Вакыты | Кем җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәпкә хәзерлек төркемендә укыту-тәрбия эшенең торышы, индивидуаль эш алып бару. | Апрель | мөдир |

## Тематик тикшерүләр

| № | Эчтәлек | Вакыты | Кем җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Бакчада балалар бакчасы шартларында балаларның сөйләм үсеше. (кечкенәләр төркеме) | Ноябрь | Мөдир |
| 2. | ФГОС таләпләре нигезендә балалар бакчасында интегральләштергән белем бирү эшчәнлеген оештыру | Январь | Мөдир |
| 3. | УМК материалларының шөгыльләрдә кулланышы | Март | Мөдир |
| 4. | Мәктәпкә хәзерлек төркемендә балаларны рус теленә өйрәтү буенча эшнең нәтиҗәлелеге. | Май | Мөдир |

## Оператив тикшерү

| № | Эчтәлек | вакыты | Кем җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Укыту-тәрбия планнарының сыйфаты | Ел дәвамында | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Тәрбияченең шөгыльгә әзерлеге | Ел дәвамында | Мөдир |
| 3. | Адаптация | Ел дәвамында | Мөдир |
| 4. | Режим процессларын оештыру | Ел дәвамында | Мөдир |
| 5. | Шөгыль төзелеше сыйфаты | Ел дәвамында | Мөдир |
| 6. | Иртәнге гимнастика сыйфаты | Ел дәвамында | Мөдир |
| 7. | Туклану культурасына анализ | Ел дәвамында | Мөдир |

**Балаларның юл-транспорт травматизмын кисәтү өчен балалар бакчасының профилактик эше.**

| № | Мероприятие | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | “Юлда хәрәкәт итүче транспортлар белән танышу.Авыл урамы белән танышу | сентябрь | Тәрбияче |
| 2.<br>3. | Арча районы ЮХИДИ идарәсе профилактика бүлеге мөдире Э.Г.Мөхәмммәтшина белән очрашу, әти-әниләр һәм балалар катнашында КВН. | октябрь | Тәрбияче |
| 4. | Юл билгеләре белән танышу | ноябрь | Тәрбияче |
| 5. | “Өч күзле батыр.” Әкият | Январь | Тәрбияче |
| 6. | “Кызыл, сары, яшел” – күңел ачу кичәсе. | февраль | Тәрбияче |
| 7. | “Яшел ут” конкурсында катнашырга<br>1) Иң яхшы рәсемгә конкурс “Транспорт төрләре”.<br>2) Балалар белән интеллектуаль уен оештыру “Нәрсә?” “Кайда?” “Кайчан?” (юл йөрү кагыйдәләре буенча). | март<br><br>Ел | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Юл йөрү кагыйдәләре буенча почмакны яңа пособиеләр, дидактик уеннар белән яңартырга. | дәвамында | Тәрбияче |
| 8. | “Игътибар-балалар» стенгазета | Ел дәвамында | Бакча коллективы |
| 9. | “Юлда йөри беләсеңме? Эшлекле уен. | Апрель | Тәрбияче |
| | Йомгаклау. “Дидактик уеннар” | май | Тәрбияче |

**Бакчада эшләүче хезмәткәрләр белән коллектив җыелышлары**

| | Эчтәлек | вакыт | Җавапл |
|---|---|---|---|
| 1. | 1.Яңа уку елына әзерлек.<br>- Бакчаның хезмәтне саклау буенча эчке тәртип кагыйдәләрен беләсеңме?<br>- Бакчада электр приборларының кулланышына игътибарлы бул!<br>- Балаларның сәламәтлеге,тормыш иминлеге безнең кулда.<br>- Бакчаның эчке һәм тышкы матурлыгы бар хезмәткәрләрнең дә җаваплылыгында. | Сентябрь | Мөдир |
| 2. | 2 .Яңа ел алды әзерлеге.<br>- Кышкы чорда балаларның тормыш иминлеген,сәламәтлекләрен саклау барыбызныөң төп бурычы.<br>- Яңа ел бәйрәме уздыру буенча техник куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтә.<br>- СанПИНның кагыйдәләрен искә төшерик. | Декабрь | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | 3.Язгы эшләргә әзерлек.<br>- Бакчаның тышкы матурлыгы ,бар хезмәткәрләрнең дә җаваплылыгында.(өмәләр, чәчәк үсентеләре,агачлар утырту һ.б.)<br>-Балаларның сәламәтлеген витаминлы ризыклар белән баетыйк.<br>-Балаларның авыртучанлыклары турында чагыштырмача анализ. | Март | Мөдир |
| 4. | 4.Бакчаны косметик ремонтлау.<br>- Җәйге сәламәтләндерү планы белән хезмәткәрләрне таныштыру.<br>- Отпуск вакытында бакча участогын карау өчен дежурлар билгеләү. | Июнь | Мөдир |

## Оештыру эшләре.

| № | Эчтәлек | вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Традициягә кергән бөтен Россия бәйрәмнәрен үткәрү<br>- Өлкәннәр көне-1 октябрь<br>-Халыкара гаилә көне-15 май<br>-Халыкара балаларны яклау көне-1 июнь | Ел дәвамында | Мөдир, тәрбияче |
| 2. | **“Көзге могҗиза””**<br>иҗат конкурсы оештыру | октябрь | Мөдир, тәрбияче |
| 3. | **“Минем әни иң гүзәле”** Фотоконкурс | ноябрь | тәрбияче |
| 4. | **“Без җәяүлеләр”** рәсем конкурсы<br>**“Йолдызлык”** смотр-конкурсы<br>”Голосок” район, вокал, конкурсында катнашу. | декабрь | мөдир Тәрбияче |
| 5. | **Балаларның ата-анасы белән эшләгән кул эш-ләре һәм гаилә фотографияләре конкурсы** | февраль | Тәрбияче |
| 6. | Юл йөрү куркынычсызлыгын үтәү һәм юл травматизмын кисәтү уңаеннан үткәрелгән районның **“Яшел ут”** конкурсы. | март | мөдир, тәрбияче |
| 7. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның **Г.Тукайның** туган көненә багышланган шигырьләр сөйләү конкурсы<br>“Каблучок” район, бию, конкурсында катнашу. | апрель | Мөдир, Тәрбияче |
| 8. | Юл куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү<br>Һәм юл травматизмын кисәтү турында чара **Җиңүнең** уңаеннан үткәреләчәк | май | Тәрбияче, ЮХИДИ хезмәткәр- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | “Һәрвакыт булсын кояш!” конкурсы | | ләре |
| 9. | Балалар бакчасында җәйге сәламәтләндерү Һәм ял итүне оештыру. | июнь | коллектив |
| 10. | Мәгълүмат чарасы һәм методик әдәбиятка Язылу | 6 айга 1 тапкыр | Мөдир |
| 11. | Ведомстводан тыш органнар белән тыгыз элем-тәдә эшләү:Үзәк хастәханә,ЮХИДИ,авыл советы, янгын куркынычсызлыгы органнары һ.б.) | Ел буе | Мөдир |

## Кадрлар белән эш.

| № | Эчтәлек | вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Хезмәтне яклау буенча инструктаж, балаларның сәламәтлеген һәм тормышын саклау буенча инструктаж. | сентябрь | Мөдир |
| 2. | “Эчке хезмәт кагыйдәләре” турында сөйләшү уздыру,производство җыелышы. | сентябрь | Мөдир |
| 3. | Яңа САНпин таләпләре белән танышуны ныгыту | сентябрь | мөдир |
| 4. | Хезмәт урыны инструкцияләре үткәрү. | сентябрь | Мөдир |
| 5. | Тәрбияче белән эшләү.Тәрбия эше буенча аңлату эшләре алып бару. | сентябрь | Мөдир тәрбияче |
| 6. | Гадәттән тыш вакыйгалар, террорлык актлары вакытында хезмәткәрләр белән нишләргә кирәклеге турында сөйләшү үткәрү. | октябрь | Мөдир |
| 7. | Балалар бакчасы бинасын кышка әзерләү, тәрәзәләрне ябыштыру, территорияне җыештыру. | октябрь | Коллектив |
| 8. | “Яңа ел” бәйрәмен уздырганда | декабрь | Коллектив |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү. | | |
| 9. | Педагогик әдәбияттагы яңалыклар турында фикер алышу. | февраль | Тәрбияче, мөдир |
| 10. | Бакча участогы турында кайгырту. | апрель | Коллектив |
| 11. | Бакча территориясен яшелләндерү. | май | Коллектив |
| 12. | Хезмәтне яклау буенча хезмәткәрләрне укыту. | 6 айга 1 тапкыр | Мөдир |

## Методик эш

| № | Эш төре | Вакыты | Жаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Бакчаны педагогик кадрлар белән тәэмин итү. | август | мөдир |
| 2. | Бакчаны яңа уку елына әзерләү. | август | мөдир |
| 3. | Узган уку елындагы эшчәнлеккә анализ ясау. Бакчаның яңа уку елына еллык белем-тәрбия планын төзү, кабул итү. | август сентябрь | мөдир, тәрбияче |
| 4. | Хезмәткәрләрнең хезмәт бүленешен раслау, тарификация белән таныштыру. | сентябрь | мөдир |
| 5. | Төркем бүленешен, шөгыльләр челтәрен төзү, раслау. | сентябрь | мөдир тәрбияче |
| 6. | Семинарларда, утырышларда катнашу. | даими | тәрбияче |
| 7. | Район методик берләшмәсе оештырган конкурсларда катнашу. | план буенча | мөдир, тәрбияче |
| 8. | Мәктәп белән балалар бакчасы арасындагы дәвамчанлыкны үстерү. | даими | мөдир, тәрбияче, |
| 9. | Экологик тәрбия өчен материалларны туплау, тулыландыру. | ел дәвам-а | мөдир, тәрбияче |
| 1 | Методик почмакны яңа методик әсбапләр, күрсәтмә материаллар, газета-журналлар белән тулыландырып тору, баету буенча эшләү. | дәвамлы | мөдир тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | Укыту-тәрбия эшен ФДББС на туры китереп алып бару. | Ел дәвамында | тәрбияче |
| 12. | Эш юнәлешләре буенча тәрбиячене портфолиоларын тулыландырып бару. | ел дәвам-да | тәрбияче |
| 13. | Аттестация папкасын яңарту, тулыландыру. | сентябрь | мөдир |
| 14. | Сөйләм үстерү шөгыльләре өчен картотекаларны яңарту, тулыландыру. | сентябрь | тәрбияче |
| 15. | Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча альбом, кулланма җиһазлар булдыру, тулыландыру. | сентябрь | тәрбияче |
| 16 | Балаларга рус телен өйрәтүне яңа алымнарга таянып эш алып барырга. | даими | тәрбияче |
| 17. | Сәнгать шөгыльләре өчен табигый материаллар, күрсәтмә, кулланма җиһазлар туплау. | даими | тәрбияче |
| 18. | Балаларның сәламәтлеген ныгыту өчен дару үләннәре җыю, гербарий ясау, кулланма җиһазларны тулыландыру. | җәй айлары | коллектив |
| 19. | Бүлмәләрдә дәвалаучы гөлләр үстерү. | даими | тәрбияче |
| 20. | Балаларны районыбызның, җирлегебезнең данлыклы шәхесләре белән таныштыру өчен материаллар туплауны дәвам итү. | даими | тәрбияче |
| 21. | Дидактик уеннарны яңарту. | даими | тәрбияче |
| 22. | Халкыбыз тарихы – борынгы әйберләр белән таныштыру өчен материаллар туплау, авыл музеена экскурсия оештыру. | даими<br>февраль | тәрбияче, музей җитәкчесе |
| 23. | Балалар бакчалары арасында үткәрелүче конкурсларда катнашу. | ноябрь | мөдир, тәрбияче |

## Административ –хуҗалык эшләре

| № | Эчтәлек | вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Бинаны яңа уку елына<br>әзерләү, уен мәйданчыкларын матурлау, актлар язу. Балалар бакчасының материаль-техник базасын – уенчыклар,мебельләр белән тулыландырырга | Июнь-август | Коллектив |
| 2. | Балаларны “элекрон детский сад”та барлау. | сентябрь | Мөдир,методист |
| 3. | Балалар бакчасы хезмәткәрләренә инструктажларга ,укытып кул куйдыру | сентябрь | мөдир |
| 4. | Балалар бакчасы эшчәнлеге турында опера-тив һәм статистик информацияләр бирү.<br>(форма №40, форма №85 ) | Сентябрь, январь, июнь | Мөдир |
| 5. | Ата-аналар белән,педагогик киңәшмәләр уздыру.<br>Коллектив җыелышлары уздыру.Тематик , оператив тикшерүләр. | План буенча | Мөдир,фельдшер тәрбияче |
| 6. | Хезмәтне яклау турында приказ язу һәм җаваплы кеше билгеләү | сентябрь | Мөдир |
| 7. | Балалар бакчасының төп күрсәткечләренә контроль ясау.(балаларның бакчага йөреше планының үтәлүе,<br>авыручыларның санын киметү,туклануны оештыру,ата-аналарның ва-<br>кытында түләве, балаларның имгәнүен кисәтү) | Айга 1 тапкыр | Мөдир |
| 8 | Норматив документлар һәм локаль актлар-ны тәртипкә китерү | октябрь | Мөдир |
| 9. | Балалар бакчасының эшчәнлеге турында мәгъ-лүмат әзерләү , белешмә язу.(тәрбиченең дәресен,<br>балаларны уйнатуын, саф һавада йөрешен карау һәм анализ ясау) | Айга 1 тапкыр | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Кыш айларында керү -чыгу юлларын кардан чистартып тору. | Декабрь-март | мөдир |
| 11. | Язгы чорда түбәдән кар төшерү. | Март-апрель | мөдир |
| 12. | Бакчаны чүп-чарлардан чистарту.Чәчәкләр утырту. Бакчаның территориясен тәртипкә китерү, уен мәйданчыкларын матурлау һәм яшелләндерү. | Май | мөдир |
| 13. | Агымдагы ремонт эшләре өчен материаллар булдыру. | июнь | мөдир |
| 14. | Балалар бакчасының уен мәйданчыгында ремонт эшләре. | Июль-август | мөдир |

## Күргәзмәлекләр

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Район күләмендә оештырылган конкурсларда катнашу | Даими | тәрбияче |
| 2 | “Көзге байлык” – яшелчә, җиләк – җимештән күргәзмә | Сентябрь | тәрбияче |
| 3 | **“**Авылым чишмәләре” рәсем конкурсы оештыру | Октябрь | тәрбияче |
| 4 | “Минем әни иң гүзәле” фотоконкурс | Ноябрь | тәрбияче. |
| 5 | Яңа ел бәйрәмендә кулдан ясалган уенчыклар белән бүлмә бизәлешенә конкурс. | Декабрь | тәрбияче |
| 6 | “Ур-ра кыш килде” боздан сыннар Ясау | Декабрь | тәрбияче |
| 7 | “Серле куллар” - әбиләргә, әтиләргә һәм әниләргә балалар кулы белән эшләнгән бәйрәм бүләге .<br>“Оста куллы әтием” күргәзмә | Февраль,<br>Март | тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Г.Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр | Апрель | тәрбияче |
| 9 | “Минем гаиләм” – әвәләү конкурсы | Май | тәрбияче |

## Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, тарату

| | **Эш төре** | **Вакыты** | **Җаваплы** |
|---|---|---|---|
| 1 | Район күләмендә үткәрелгән КМО һәм РМОутырышларында, семинарларда катнашу һәм тәҗрибә уртаклашу ,чыгышлар ясау | Даими | Мөдир, тәрбияче |
| 2 | Район, республика күләмендә чыга торган газета журналларга үзенең эш тәҗрибәсен язып тарату | Даими | Мөдир, тәрбияче, |
| 3 | Тәрбиячененең эш тәҗрибәсе буенча китапчыклар ясау, район – республика күләм таратуда матбугат чараларыннан һәм интернеттан файдалану. | Даими | Мөдир, тәрбияче, |

## Мәктәп белән берлектә эш.

1. Мәктәпкә керүче балаларны, мәктәп программасы белән таныштыру.
2. Ачык ишекләр көне (тәрбиячеләр,укытучылар бакча шөгыльләрендә катнашуы).
3. Ата-аналар белән эш, “1 нче сыйныф баласы нәрсә белергә тиеш?”
4. Баланың мәктәпкә хәзерлеге (укытучы, укучылар белән очрашу).
5. Рус телен үстерү өстендә эшләү.

## Ата-аналар җыелышлары

| № | Җыелышның эчтәлеге | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | 1. “Әйдәгез, танышабыз.” Балалар бакчасында адаптация чоры.<br>2. Ата – аналар комитетын сайлау. | август | Мөдир<br>тәрбияче |
| 2. | 1.Урам тәрбиясе начармы?.(доклад)<br>2. Кечкенә балалардагы авырулар.(Үзәккә үткән аллергия) | декабрь | Мөдир<br>тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3. Яңа ел бәйрәме кичәсе | | |
| 3. | 1. Баланы мәктәпкә ничә яшьтә бирергә? (доклад)<br>2. Ни чәчсәң, шуны урырсың. Балагыз белән дөрес аралашасызмы?(анкета уздыру)<br>3. Җәйге сәламәтләндерү планы. | май | Мөдир<br>тәрбияче |

## Ата – аналар белән индивидуаль эш

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Уку елы башында балаларның өйләрендә булу, гаилә хәлләре белән танышу, бакчага тарту. | сентябрь | тәрбияче, мөдир |
| 2 | Иртән балалар китергәндә һәм кич килеп алганда ата – аналар белән әңгәмәләр, консультацияләр үткәрү. | даими | Тәрбияче |
| 3 | “Ачык ишекләр” көне үткәрү. | ноябрь, март | Тәрбияче |
| 4 | Юлда йөрү, пожар куркынычсызлыгы кагыйдәләрен өйрәнүне дәвам итү. | даими | Тәрбияче |
| 5 | Балаларда шәфкатьлелек, әдәплелек, миһербанлылык тәрбияләү. | даими | Тәрбияче |
| 6 | Балаларда үз – үзләренә хезмәт күрсәтергә өйрәтүне дәвам итү. | даими | Тәрбияче |
| 7 | Бәйрәмнәрдә конкурсларда актив катнашу. | даими | Тәрбияче |